**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Урсаевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, д. 60, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального района,
423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

Үзәк урам, 60, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» ноябрь 2021 ел №7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам**

1. 28.11.2021ел Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Меслим торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 28 нче ноябрь 2021нче ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Меслим авылы, Гафури ур. , 31 йорт, Меслим авыл мәдәният йорты янында ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021нче елның 17 нче ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 нчы йорт;
- сайлау хокукына ия булган Мөслим торак пунктында яшәүчеләр исемлеген

төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Меслим торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 нче елда Мөслим авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Беек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә, 2 нче теркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 250 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Мөслим авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр кене», «Инвалидлар декадасы», «Яңа ел»,);

- Мөслим авылы территориясен тезекләндерүне оештыру (тракторчыга карны механикалаштырып җыю, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү);

-җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (мәчет, авыл клубы, ФАП һәм балалар бакчасы территориясе),территорияне механикалаштырылган чабу хезмәте өчен түләү, килешү буенча эшләр, ягулык-майлау материаллары һәм тример өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту, территорияләрне яшелләндерү чаралары, Мафлар сатып алу һәм урнаштыру.,

- халыкны су белән тәэмин итүне оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, ЗСО чыганакларын төзекләндерү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәтләр ечен түләү, Мөслим авылында эчә торган суны биохимик һәм бактериологик анализлау үткәрү);

- Мөслим авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларга вак таш җәю, таш салу, вак таш җәю, Мөслим авылында Гафури урамы, 3 - 27 нче йорт буенча төзелгән килешү буенча түләү);

- Мөслим авылы христиан зиратын киртәләп алу, койма ясау һәм урнаштыру.;

- Мөслим авылында урамнарны яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мөслим авылы, Такташа ур., 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үл халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: З.Х.Рахимьянова